Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

ЧАЯН



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ИЮЛЬ * 2021 * КАЗАН

7

Вячеслав БИБИШЕВ



20 нче битне карагыз

Алмаз ХӘМЗИН

ҮСМИ КҮҢЕЛ

Үсми күңел, үсми нигәдер...
Сорыйм әле, Ходай беләдер?
Ник мин моңсу, кемнәрдер бик көр,
Күктә бит Ул, бәлки, күрәдер?..

Үсми күңел, һаман пошына,
Ошаса да сәмруг кошына.
Безгә бәхет ташый алмый шул,
Һәйкәл генә хокук каршында.

Үсми күңел, халкым язмышы,
Һәлакәткәме әллә барышы?..
Кояшыбыз бата, елмаймый
Һәм дә моңсу бик тә калкышы.

Үсми күңел, белмим, үсәрме...
Йоклый алмый чыгам төннәрне.
Йолдыз атылганга бәхет юрап
Яшәү яңарырмы, бетәрме?..

Үсми күңел, көн-төн мактану,
Ә чынлыкта гамьсез таптану.
Чүт-чүт сайрый телевизорда
Бер ата кош, җыры – аклану.

Үсми күңел, нигә үссен соң?..
Кайдан, кемнән очкын чыксын соң?
Ялкынланып яшәү нияте
Чыгып качкан икән күрәмсең?

Үсми күңел, сулган тамыры,
Ышанычы беткән – коп-коры...
Ул гынамы дучар бу хәлгә, –
Сәбәпләр күп, каһәр суккыры!

Үсми күңел, бәлки үсәр бер,
Килер андый көннәр барыбер.
Ил-йорт арынып хаксызлыктан –
Җаныбызга сихәт сарылыр!

БЕРӘҮ

Ничек яши әле һаман
татар?!
Бетәргә тиен булган бит
күптән...
Әллә беткәнме чынлап та –
дәшми,
Әллә соң гомере... куркып
үткән...

Бер мин калганмын ахрысы
исән...
Ниләр бар дөньяда икән
дисәм –
Түрәләр клоун "күлмәге"
кигән,
Депутатлар ялчылыкка
күнгән.

Әйбәт кешеләр кырылып
беткән...
Капшыйм үземне – икәнмен
тере.
Җир Шарына басып торган
Берәү –
Мин калганмын хак язучы
тиле,
Сукалаучы бар нәрсәне
кире.

Игорь КИЙКО



ШОМБАЙ

болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Тормышыбыз шулкадәр үзгәрде ки, хәтта ияләнеп беткән әйтемнәр һәм мәкальләр дә тәүге мәгънәләрен югалталар. Кайчандыр ярлы кеше турында "ул кишердән татлырак әйбер ашамаган", дип әйтә торган булганнар. Бүген исә Казанда бу сүзләр тормышка туры килми. Күптән түгел генә кибет киштәләрендә аунап яткан тамыразык затлы тәм-томга әверелде. Җәй башыннан аның бәясе йөз сумга күтәрелде, һәм бүген базарда кишернең килосын 130-180 сумга гына алып була. Ә кибетләрдә ул гомумән юк. Бәяләрнең кискен үзгәрешен беркем дә юньләп аңлата алмый. Кемнәрдер корылыкка сылтый, икенчеләр сәбәпне кыргый базар тәртипләрендә күрә, ә кайберәүләр сайлаулар алдыннан дошманнар казынуына ишарә ясый...

М. ШӘЙХИЕВА

КАЗАН

Хөрмәтле Шомбай ага укучыбызның хатын укып чыкты да, үз фикерен әйтеп тә бирде.

– Кишер бәясе аны коронавирус аркасында метр ярымлык ара белән утырта башлаганнан күтәрелгәндер, – диде ул.

БУЛА АЛМАДЫМ...

Хәмер белән иҗат бертуганнар –
Күптән миңа мәгълүм бу чынлык.
Шәраб йоткач кына юкка чыга
Күңелдәге соры туң тынлык.
Күп шагыйрьләр даһи шигырьләрен
Язганнар, ди, "йөзеп галәмдә".
Пушкин хәмер сөйгән, дип сөйлиләр,
Баш тартмаган, имеш, Хәйям дә...

...Кәгазь алып, каләм кимермичә,
Бер кичем дә минем үтмәде,
Шешә төпләрендә илһам эзләп,
Ничә тартма шәраб "бөкләнде"...
Ошбу эчемлекләр өлкәсендә
Бөекләрдән артта калмадым.
Тик, нишләптер, күпме хәмер эчеп,
Гомәр Хәйям була алмадым...

Ринат АБЗАЛОВ



Илдар НӘФИЕВ



Сергей АНДРИАНОВ

Алдау йолдызлыгы астында

Берзаман миңа бер газетада астролог булып эшләргә туры килде. Рәхәт, тук чаклар, мул итеп түлиләр – йолдызларны бик әйбәт белмәсәм дә, редакция кассасының кайда икәнен бик шәп беләидем. Ул гына түгел, ул йолдыз фаразлары белән ярыйсы гына экономия ясарга да мөмкинлек бар. Хатынның яңа тун турында сүз чыгаруы була, икенче көнне газетамны күренә торган җирдә калдырып китәм. Ә анда язылган: "КУЧКАР. Хатын-кызларга киләсе елның ахырына кадәр кыйммәтле әйберләр алудан тыелып торырга һәм вакытларын гаиләгә һәм йорт хуҗалыгына багышларга тәкъдим ителә."

Өстәвенә, әле мине телевидениегә төрле астрологик программаларга чакырып тордылар. Белсәгез иде минем клиентларны! Банкирлар, ресторан хуҗалары, зур түрәләр... Ресторан хуҗалары, гадәттә, конкурентларына каршы прогнозларга заказ ясыйлар. Мисал өчен, "Фасоль" кафесының хуҗасы күршедәге "Кызыл үгез"не яптырырга тели икән, минем янга конверт тотып килә, ә икенче көнне газетада укый: "Быел тикшерелмәгән ризык ашап агуланудан сакланырга кирәк. Бигрәк тә исемнәрендә төсләр һәм хайваннар искә алынган туклану предприятиеләреннән ераграк йөрергә кирәк. Исемнәрендә кузаклы культура исемнәре булган кафеларда туклану хәерлерәк..." Нәтиҗәдә, "Фасоль" чәчәк ата, ә "Кызыл үгез" бөлә, таркала... йә минем янга килә.

Ә түрәләр! Алары килмиләр, минем арттан машина җибәрәләр, һәм коньяклы өстәл янында үтенечләре белән мөрәҗәгать итәләр. "Астролог әфәнде, уникенче йорт янында торган кирәксез агачлардан котылып, ничек анда 500 машиналык автостоянка төзергә икән? Инвалидлар өчен өч урын белән! Табигать саклаучылар бик борчый... Йолдызлар бу турыда нәрсә уйлый икән? Мин үзем Кәҗәмөгез..." Алдында мең доллар ята икән, йолдызларның нәрсә уйлавы мөмкин соң? Мин, башымны селкеп, акчаны алып куям, өстәлгә карталар таратам. Биш минутлап фикер җыйганнан соң коньяк йотып куям һәм башлап җибәрәм: "Менә бу төсле түгәрәкне күрәсезме? Кешеләр, гадәттә, күрәләр. Ә мин үзем аның нәрсә икәнен дә белмим." Ә аннан соң үзеннән-үзе китә: "Тылсымлы таң атуның пентакленнән ясалган мандала бу. Ул безгә нәрсә сөйли? Бөтен финанс мәсьәләләре сезнең файдага хәл ителәчәк. Өстәвенә, сез күптән түгел бакчада үсеп утырган авыру агачларны күргәнсез. Аларның газабы сезгә дә күчкән. Ул авыру башкаларга да таралмасын өчен, агачларны кисеп ташларга кирәк." Түрә-Кәҗәмөгез җиңел сулап куя. Кешеләр, бигрәк тә Кәҗәмөгезләр, мондый киңәшләрне яхшы кабул итәләр. һәм аларга колак салалар...

Ә икенче көнне 12 нче йорт турындагы фаразларым басылып чыга. Әгәр янәшәдәге авыру агачлар киселмәсә, котточкыч эпидемия башланачак. Безнең халык беркатлы бит – бер көн эчендә агачларның эзе дә калмады. Соңыннан ул урыннан узып китәргә туры килде – карыйм, автостоянка эшләп ята, Кәҗәмөгезем дә шунда йөри. Туктап, түрә янына бардым. Рәхмәт укый, барысы да менә дигән, йолдызлар ярдәм итте, ди. Тик менә инвалидлар өчен генә урын табылмаган икән. Мин аңа бу очракта кармасының кимүе мөмкинлеген исенә төшерәм. "Аның каравы, табыш арта, – ди бу миңа. – Әйдә, синең кармаңны зурайтыйк." Рестораннга кереп, кәеф-сафа кордык, ә минем кармам тагын мең долларга артты...

Ә соңыннан киттем мин ул астрологиядән. Кешеләрне алдау туйдырды. Үземә башка шөгыль таптым – тренинглар һәм мастер-класслар. Шул ук эш, бары исеме генә башка. һәм "мандала" ише аңлаешсыз сүзләр дә кирәк.

Йолдызларны онытмадым – мин аларга хәзер болай гына карарга яратам. Сөйгән кешеңне кочасың да, бернинди исәп-хисапсыз гына сокланып карап утырасың. Оныта язганмын – минем хатын-кызлар өчен мастер-классыма рәхим итегез. "Ничек сылу булырга, ябыгырга, карьера ясарга, баерга, балаларны тәрбияләргә, күкрәкләрне зурайтырга һәм миллионерга кияүгә чыгарга" дип атала. Бөтенесе дә бар, вакланып тормыйм. Үзең белән 10 мең сум гына булсын.

Кыйммәт булса да, ниһаять, хатынга тун алырга җыенам. Алайса һаман иске кучкар белән йөри...

Илья КРИШТУЛ





Россиянең ике союздашы бар – Петров һәм Бәширов







Валерий ТАРАСЕНКО рәсемнәре



• • •

Кызык вакытта яшибез: Ramstein клибы өчен – 2,5 ел колония, ә Бузова клибына – Муз-ТВ премиясе.

• • •

– О, сәлам! Син кайда хәзер?

– Ничек булдыра алам, шулай бөтерелəм. Бизнесым бар минем. Күчемсез милек белән шөгыльләнәм.

– Шулаймыни, әбиеңнең өч бүлмәсенә квартирантлар кертәсеңме?

– Әйе.

• • •

Бераүгә дә начарлык теләмәгез, чөнки ул үзегезгә әйләнеп кайта. Мәрхәмәтлек кылыгыз, ул беркайчан да кире кайтмаячак.

• • •

Хатыны – иренә:

– Минем сиңа яхшы хәбәрем бар!

– Нинди?

– Син машинага страховка юкка сатып алмагансың икән!

• • •

Шундый хәбәр йөри: Иван Царевич Кощей Бессмертныйны үтерергә Пенсия фонды тарафыннан җибәрелгән икән бит.

• • •

Һич тә аңлашылмый, ни өчен көнбатыш алмаларын һәм помидорларын сытарга кирәк, ә айфоннары белән компьютерларын – юк?!

• • •

Сбербанк үзенең бүлекләрендә даруханә пунктлары ача. Хәзер һәр клиент, мошенниклар аның акчасын урлаганнарын белеп һәм дә инде аңа бераү дә булышмаячагын аңлап, валидолны җайлы гына шунда ук сатып алачак.

• • •

– Мин, әтием кебек, ай саен бер миллион эшләп алырга хыялланам!

– Нәрсә, ул шулхәтле эшлиме?

• • •

– Бер ир-атның битлегендә мондый язу күрдем: "Монда Сезнең рекламагыз булырга мөмкин!" Юк, ул хыяллана гына!

Дамир МОРТАЗИН

"ЭШ КЕШЕСЕ"

Гомуми сораулар һәм җаваплар урынбасары Боламыков кабинетына шыпырт кына секретаршасы керде.

– Нәрсә сиңа? – дип сорады аннан шефы ачулы тавыш беләнрәк, компьютерыннан күчкә аерылып.

– Шәһәр телефонынннан шалтыратталар, сезнең исем-фамилиягезне сорап.

– Ә син нәрсә дидең? – дип шикләнебрәк куйды Боламыков, сайттагы якты йолдызлар, йолдызчыклар турында онытып.

– Сезнең Үзегездән рөхсәт алыйм әле, дидем...

– Дөрес! Башта кем шалтыратканын белеш, нәрсә кирәк икән аңа...

Секретарша, кергәндәгедәй, шыпырт кына чыгып китте, ә Боламыков яңадан мониторына төбәлде. Кайчагында пышылдап:

– Монысы да шул өлкәдән... Беркайчан да уйламассың... Кара инде бу сөйрәлчеге сәхнәдә ниләр кылана? Берәрсе белән йоклап чыккандыр әле... Кем белән икәнен беләм бит...

Бераздан аның каршысына яңадан секретарша килеп басты.

– Белдеңме кем икәнен һәм ни өчен мин аңа кирәк? – дип, бик җитди сорады аннан Боламыков.

– Ул сезнең аңа зур мәрхәмәтлек күрсәткәнегезне әйтте һәм шуның өчен сезгә Рәхмәт хаты юлларга теләге барлыгын белдерде, ә исем-фамилиягезне белми.

– Нишләп интернеттан тапмый?

– Компьютер белән бик дус түгел икән, интернетны да белми. Нәрсә әйтим соң аңа?

– Тукта әле, – диде дә Боламыков, хәтеренә кемнәргә кайчандыр булышуын искә төшерергә кереште. Андыйлар бик аз икән – туганнары, сөяркәләр һәм кирәкле кешеләре генә. Ләкин алар аны үзләренең биш бармагы шикелле беләләр... "Кем булырга мөмкин бу?" – аптырады-йөдәде Боламыков.

– Нәрсә дип әйтим соң инде? – диде түземсезләнеп, янында басып торган секретарша.

– Бернәрсә дә әйтмә! Ул мине кем беләндер бутаган...

Секретарша чыгып китте. Ә Боламыков бераздан бөтенләй тынычланды. "Әлбәттә, бутаган, мин чит кешегә яхшылык эшли торган кешеме инде..."

Ул яңадан мониторга текәлде. Эш көне кайный торган чак, ә интернетта кызыклар – море...

Михаил ЛАРИЧЕВ




СҮЗ ИЯРӘ СҮЗ

- Шагыйрьне аның шигырьләре яза.
- Ир – хатынның хезмәтчесе, хатын – ирнең ялчысы.
- Ялган фирма мәңге эше уңмас беркатлы кешеләр эзли.
- Кешечә әйтсәң, хайван да аңлый.
- Кайчан да булса Җир кеше хакимлегеннән котылыр.
- Барган юлы язмышка гел туры килеп кенә тормый.
- Ахмак хезмәт итә, акыллы эш күрсәтә.
- Тапталган пычрак – ул барыбер юл түгел әле.
- Тормыш мәсьәләләре җыентыгында бөтен биремнәр дә йолдызчык белән.

Юрий ТУБОЛЬЦЕВ

Виктор БОГОРАД







ЭЛЕК ҺӘМ ХӘЗЕР...

"Алдынгылар сайлансыннар
Совет аппаратына!" –
Дип жырлыйлар иде элек,
Советлар вакытында.

Хәзер инде башка заман –
Властьта ЕдРоссия!
Алар үрнәк күрсәтсеннәр,
Кадатканда вакцина!

Алмаз ХӘМЗИН



Михаил ФИЛОНОВ

РАЙОН ДӘВАСЫ

Авыру, гадәттә, мәхәббәт кебек, көтмәгәндә килә. Менә минем дә кинәт кенә үпкәм ялкынсынып китте. Табиб башын селки-селки буылып ютәлләвемне һәм күкрәгемдәге гыжлауны тыңлап торды да, кисеп салды:

– Район хастаханәсенә җыеныгыз!

– Ә өйдә генә ярамыймы? – дип сорадым мин калтыранган тавыш белән. – Безнең җәһәннәм тишегеннән район үзәгенә барып җиткәнче тәпиеңне сузарга мөмкин бит...

– Хастаханәгә никадәр тизрәк барып җитсәгез, сезнең тәпиләрегезгә шулкадәр яхшырак булыр, – диде табиб коры гына.

Мин районга ничек барып җитү турында уйлый башладым. Җәяү булмый, машинам юк — «ашыгыч ярдәм» чакыртырга булдым. Кызыл хач машинасы тиз килеп җитте – мин шалтыратканнан соң дүрт сәгать кенә үтте бугай. Медицина әһелләре минем әле сулап ятуыма бик гаҗәпләнделәр, ә район хастаханәсенә барырга җыенганымны белгәч, бөтенләй аптырашта калдылар. Алар миңа инде ярдәм кирәк булмас, дип уйлаганнар, ахрысы.

Сикәлтәле юлда машина очып-очып китсә дә, мине исән килеш китереп җиткерделәр. Ике атна буе палатада дистәләгән уколлар кадап, берничә кап дару эчерткәннән соң мине аякка бастырдылар. Өстәвенә, күзеңне түшәмгә төбәп капельница астында ятарга да туры килде.

Һәм менә, ниһаять, чыгу көне килеп җитте. Аны армиядәге дембель белән генә чагыштырып буладыр. Мин инде туганлашып беткән ак халатлы туташ-түтәйләр белән хушлашам. Сизәм, беркем дә минем күземә карамый. Карашлары минем кулларга текәлгән. Хәзер бит хастаханәдә бар нәрсә өчен дә түләргә кирәк. Моны миңа процедура кабинетында арт якка укол кадаганда бик үтемле итеп аңлаттылар...

Мин мондагы гореф-гадәтләрне бозып маташмадым, ләкин персоналның күңелен күрү белән мавыгып китеп, соңгы автобуска соңга калуымны сизми калганмын. Бәреп яуган яңгыр һәм үзәк өзгеч җил астында өйгә җәяү атларга туры килде. Ә башта бер генә уй: «Ничек кенә авырып китмәскә һәм тагын бу тәмугка килеп эләкмәскә икән...»



ТИШЕК КӨПЧӘК



Сергей ЕРМИЛОВ

• • •

Инспектор машинаны туктата:


– Туташ, сез тизлекне 40 километрга кадәр чикләү билгесен күрдегезме?

– Әйе, ләкин мин аны пошилар өчен дип уйладым...

– Нинди пошилар?!

– Аның алдыннан торган билгедә ясалган...





• • •

Көне буе урамда басып торып, беркемне дә штрафка тарта алмаганга җене кузгалган юл инспекторы кашын-күзен җыерып өенә кайтып керә һәм өйдә беренче очраган кешегә – улына бәйләнә башлый:

– Бар әле, көндәлегеңне алып кил!

Малае башта әнисе янына йөгереп килә:

Әни, нишләргә икән? Минем анда ике «2»ле тора бит!

– Борчылма, улым, күрсәт, – ди анасы һәм көндәлек эченә 100 сумлык кыстыра.

Атасы көндәлекне ала, ача, аның эчендәге акчаны кесәсенә шудыра, көндәлекне яба һәм, яктырып китеп, җиңел сулап куя:

– Аллага шөкер, өйдә тәртип, ичмасам!

• • •

Гадәттәгечә элдертеп бара торгач, бер ханым машинасын җәяүлегә китереп төрттерә.

– Тагын сезмени әле бу? – ди тегесе. – Әле кичә генә мине бәреп еккан идегез ич инде!

– Зинһар өчен, гафу итегез, танымаганмын бит...









"ӨЛЕШ" КОРБАНЫ

"Свияжский" табигать тыюлыгы директоры Алексей Деев үзенең табигать саклау вазыйфалары өстенә браконьерларның күңелен күрү белән дә шөгыльләнгән. Аның карамагында булган территориядә хәтта кармак белән балык тоту да тыелган булуган карамастан, тыюлык директоры аны ятьмә белән тотучыларга да игътибар итмәгән. Үз файдасы турында онытмыйча, әлбәттә. Тотылган балыктан көн саен 200 килограммлык өлеш чыгарырга мәҗбүр булган браконьерлар үзләре табигать сакчысын тиешле органнарга тапшырганнар.

ҖИРЛӘҮ МОНОПОЛИЯСЕ

Чаллыда өч җирләү компаниясе үзара килешенү төзегән. "Горкоммунхоз" муниципаль предприятиесе һәм "Мемориал-НЧ" белән "Ритуал-НЧ" шәхси фирмалары эшчәнлекләре өлкәсенә конкурентлар кертмәскә сөйләшенгәннәр дип фаразлана. Шәһәрнең барча хастаханәләре мәетләрне алу белән бары "тик "Горкоммунхоз" гына шөгыльләнә ала дигән хатлар алганнар. "Теге дөнья эшләре" белән хокук саклау органнары кызыксына башлаган, һәм "монополистлар"ның эш урыннарында тентү оештырылган.

КИҢ КҮҢЕЛЛЕ ГАИШНИК

Казанның ЮХИДИ имтиханнар бүлегенең элеккеге башлыгы Шамил Бикушев игелекле кеше буларак дан тоткан. Түләү өчен ул машина йөртүчеләрнең белемнәрен тикшермәгән килеш категорияләр өстәп, документларга үзгәрешләр керткән. Киң күңелле гаишникны чираттагы җиңел генә таныклыгын төзәтергә теләүче белән сөйләшүләр алып барган чакта тоткарлаганнар. Бер ел эшләү эчендә ул 52 таныклык "эшкәртергә" өлгергән.

ЯСАКЛЫ БАКЧА

Чаллыдагы 29 нчы балалар бакчасы мөдире чыгарылыш альбомы өчен балаларны фотога төшерүче фотографтан аның бакчасында эшләгән өчен гонорар суммасының 20 процентын таләп иткән. Риза булмаган очракта мөдир ханым аны шәһәрнең башка бакчалар алдында профессиональ репутациясен бозу белән куркыткан. Бу хәлдән соң җитәкчегә ышаныч югалу сәбәпле, аңа эш урыны белән хушлашырга туры килгән.

Александр БРЮХАНОВ

Катлаулы тормыш

Түшкәев, телевизор каналларын алыштырып, үзгәреп торучы сурәтләрдән ләззәт алып диванда җәелеп ята иде. Кинәт аның игътибарын ниндидер картлачның йөзе җәлеп итте. Ул пенсионерларның авыр тормышы турында сөйли иде... Түшкәевнең кинәт корсагын яндырып алгандай булды, ул, дулкынланып, диваннан сикереп торды һәм суыткычта яткан бөтен продуктлардан катлы-катлы бутерброд ясады. Ләкин күптән түгел шул ук телевизордан ишеткән организмга кирәкле продуктлар белән генә тукланып картаюны туктату турындагы сүзләрне исенә төшереп, туктап калды... Бутеброд өстенә өелгән әйберләрне кире урыннарына салып куйды, һәм яшел салат яфрагы чәйни-чәйни, иртәгә нәрсәләр ашау турында планнар кора башлады.

Ә бу вакытта яшелчәләрнең нинди химикатлар ярдәмендә үстерелүе турында тапшыру бара иде. Түшкәевнең күңеле болганып куйды. Мондый ризык белән картлыкка кадәр яши алмавың да мөмкин бит...

Телевизорны һәм андагы җан биздергеч тапшыруларны онытып торыр өчен, Түшкәев бераз тамак чылатып алырга булды...

Ләкин стаканны иренгә тидерәм дигәндә генә, өстәлдә яткан газетадагы "Агуланасың килсә" дигән мәкаләгә күзе төште. Ул аны укып чыкты, һәм иң шәп спиртлы эчемлекләрнең дә нинди шартларда эшләнүен белгәч, тетрәнеп куйды...

Үз гомере эчендә күпме һәм нәрсә эчкәнен искә алгач, Түшкәев тагын укшып куйды һәм үзенә күптәннән дәвалана башларга кирәк дигән катгый фикергә килде. Шкафны ачып, хатынының дарулар тартмасында актарына башлады...


Тик аны телевизордан барган ялган дарулар турындагы тапшыру туктатты. Алардан дәвалану түгел, тагын да катырак авырып китәргә мөмкин икән. Ә табиб киңәшеннән башка, гомумән, барнәрсә дә кабул итәргә ярамый. Боларны ишеткәч, Түшкәев барча даруларны чүп чиләгенә илтеп тондырды...

Һәм иртәгә иртән тулаәүле клиникага барырга карар кылды. Ләкин шулчак әйбәт табибларның булмавы һәм булганнарының да дәвалау урынына авыру кешене озаграк тинтерәтеп йөртүләре турында тапшыру башланды...

Түшкәев төкереп куйды – мондый ризык, мондый дарулар, мондый эчемлекләр белән яшәгәнче ятып үләсе генә кала бит... Ә монда тагын җирләү хезмәтенә бәяләр күтәрелү турында тапшыру башланды...

Түшкәев, башын учларына куеп, мәңге яшәү турында фәлсәфә кора башлады... Тик телевизордан яңа тапшыру башланды...

Түшкәев сикереп торып телевизорны өзеп куйды, һәм алдына шешә чыгарып куеп, әр-яңадан бутерброд ясый башлады...





Ринат АБЗАЛОВ



Виктор ФЁДОРОВ



Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Бакча баласе

Сәлимә әби язны бик көтеп ала – шәһәр йортыннан тизрәк бакчага, саф һавага омтыла.

Язның бер кояшлы иртәсендә бакча өеннән чыгып килгәндә, койма артыннан ниндидер чит тавышлар ишетеп ала.

– Әби, капкаңны ач әле!

Ул аптырап кала.

– Сез кем буласыз соң? Иртә таңнан кеше борчып йөрисез.

– Без – тикшерүчеләр, комиссия. Бакчаларны карап йөрибез. Барысы да тәртиптә микән дип.

– Ә-ә, алай булгач, хәзер, – диде дә Сәлимә әби, ашыга-ашыга йортына кереп китте. Озак та үтмәде, ачкычларын күтәреп чыкты да капканы ачты.

Анда ике ир кеше һәм бер хатын кыз басып торалар иде. Кыяфәтләре бик җитди, кулларында кәгазь белән каләм.

– Нәрсә, әби, берүзең торасыңмы монда?

– Әйе, картым үлгәннән соң ялгыз калдым. Балаларым еракта. Бер юанычым калды – бакча.

– Ялгыз икәнең күренеп тора, ярты бакчаңны үлән баскан. Непорядок! Әби, син яңа законны ишеттеңме? Бакчада чүп үләне үсәргә тиеш түгел! Иначе – штраф! Ярамаганнары да бардыр әле?

– Нинди ярамаган үлән булсын ди миндә? Менә кыр бөтнеге, бик файдалы үлән, даруга – тузганак. Мин аңардан салатын да ясыйм, авырткан җирләремне дә дәвалыйм. Хәзер дару бәясен беләсез. Пинсиям җитеп бетми, даруларын да ала башласаң... Тагын менә кычыткан үсеп утыра. Анысын ашка салырга була... Юк, бернинди кирәкмәгән үлән юк бакчамда!

Шул вакытта тавык кыткылдавы ишетелде.

– Ә бу нинди тавыш? Әби, син нәрсә, әллә тавыклар да тотасыңмы? Алай булгач, ник индивидуаль предприниматель дип саналмыйсың? Налог түләргә кирәк.

– Нинди налог? Ике тавыккамы? Мин бит аларны сатарга дип асрамыйм. Шул инде, көненә ике йомырка салалар. Ашап торырга җитә. Әйттем бит, пинсиям зур түгел. Менә шулар белән тукланам.

– Бакчада тавык тотарга ярамый! – дип кырыс кисеп куйды ир кешесе. – Иначе – штраф!

– И Аллам икән! Бераз акчам җыелып барсын дигән идем, булмады. Тегесе – ярамый, монысына – штраф! – Сәлимә әби аптырашка калды.

– Әби, мунчаң да бар икән бит. Утынын каян аласың?

– Ни инде, нинди утын дип әйтим... шул, урманга барам да вак-төяк чыбык-чабык җыеп кайтам.

– Шулай микән? – дип куйды хатын кызы. – Тикшереп карарга кирәк. Вак-төяк белән генә мунча җылытып булмас. Утынын да ярамаган җирдән аласыңдыр әле?..

– Менә шулай, әбекәй, – дип сүзен дәвам итте ир кеше, – син, пенсиям кечкенә дип, безнең башны әйләндермә. Штраф салырга туры киләчәк. Кем белгән, бәлки син ул йомырканы сатасыңдыр?

Алар киту белән Сәлимә әби бик озак аптырап утырды да, бер уйга килде:

– Сатарга кирәк бу бакчаны, тавыкларын суярмын. Кайтырмын шәһәрдәге фатирыма. Нишлисең, шул, башка карчыклар шикелле, подъезд төбендә кеше тикшереп утырырга кала инде. Башкача булмый.

Шулай диде дә, өенә җыена башлады.



Абау!

МИНЕМ АДРЕСЫМ ДА, ЙОРТЫМ ДА ЮК...

Сахалинда яшәүче Александр Часнык инде өч дистә елга якын зиратта пропискада. Дөрес, аның торак мәйданы 1,5–2 метрга караганда күбрәк, ир кечкенә сарайда теркәлгән. Берничә ел элек ул янган, әмма рәсми статусына карамастан, Александрга дәүләт нинди дә булса торак бирүдән баш тарткан, алар прописка буенча фактта яшәве расланмаган, дип аңлаткан. Шаһитлар юк, ә мәрхүмнәр дәшми...

КАДЕРЛЕ БҮЛӘК

Кировта Бөтенроссия олимпиадаларында җиңүче һәм призер булган 19 укучыны мэриягә чакырганнар, анда тантаналы рәвештә аларга Грамоталар һәм кетчуп, майонез, соус тутырылган пакетлар тапшырганнар. Шау-шудан соң шәһәр хакимияте бүләкләрдә катнашы булмавын белдергән, кыйммәтле бүләкләрне иганәче биргән, дип аңлаткан. Шәһәр хакимияте исеменнән, Грамоталардан тыш, акыллы башларга башка бүләкләр каралмаган.

БАКЧАЧЫ ЯЛГЫШЫ

Башкортстанның Зилаир район үзәгендә хакимият бинасы янында киндер үсеп чыккан. Җирле халык, яңа истәлекле урында – клумба янында фотога төшереп, гадәти булмаган ландшафтлы дизайнны бәяләгәннәр. Дөрес, куакларга дәү булып үсәргә ирек бирмәгәннәр, оператив рәвештә юкка чыгарганнар. Киндернең креатив авторларын полиция эзли.

ДӘГЪВА КУРТКАСЫ

Административ-хуҗалык һәм транспорт белән тәэмин итүче учреждение Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләренә судка дәгъва белдергән. Бәхәснең чыганагы – тикшерү астында булган элеккеге Тикшерү департаментының башлык урынбасары Александр Краковскийның курткасы торган. Кагыйдә буенча, куртканың киелү вакыты чыкмау сәбәпле, һәм генерал аны ирекле рәвештә үз вәкаләтләреннән туктагач, хуҗалык бүлегенә кайтарырга тиеш булган. Дәгъваның суммасы – 84 мең 037 сум да 08 тиен.

Ринат АБЗАЛОВ







Мирзаһит тормышыннан

КАПИТАН КҮЛЕ

Авылның нәкъ уртасында "Капитан күле" дип аталган күлләвек булган. Язын һәм көзен ул җәяү дә, көпчәктә дә үтмәслек булып җәелгән. Авыл мужиклары аның белән төрлечә көрәшеп караганнар – өстенә ком да өйгәннәр, ватык кирпеч тә бушатканнар. Файдасы булмаган. Шуңа күрә бу урынны тыкрыклар белән әйләнеп узарга туры килгән. Ә менә бала-чага өчен бу күлләвек һәрвакыт чын шатлык булган. Яз көне алар җыйнак саллар ясап, диңгез кичкәндәгедәй, буйга-иңгә айкаганнар.

"Диңгез"нең исеме исә каршыда яшәгән Капитан кушаматлы кешегә багышлап бирелгән булган. Ул балачагыннан ук зур кораблар һәм ерак диңгезләр турында хыялланып, заманында диңгез училищесына керергә хыялланган. Ләкин хыялы тормышка ашмый калган, авылда да үзенә юньле эш таба алмаган. Һәм аңа, балаларның диңгез сугышларын күзәтеп, ямансулап утырасы гына калган. Шул кушаматы белән авылда картайган да Капитан...

Берзаман, хәле бөтенләй начарлангач, аның янына дуслары һәм танышлары җыелган. Тавыш-тынсыз гына утырганнар. Агарып калган Капитан түшәктә ята икән. Кинәт моңсу тынлыкны Мирзаһит бүлгән:

– Ә беләсезме, һәр капитанның үз корабы була, безнекенең генә үз күле бар!

Бу сүзләрне ишеткәч, Капитан чак кына елап җибәрмәгән – бу күлләвек турындагы истәлекләр аның җанына шулкадәр якын булып чыккан.

Ул дөнья куйгач, күлләвек кинәт кенә кибеп юкка чыккан. Ләкин бу урынны авылдашлары, килгән-киткән кешеләрне гаҗәпләндереп, әлегә кадәр Капитан күле дип атыйлар.

МАШИНА АЛГАН ВӘЛИ

Вәли һәрвакыт Мирзаһитның машинасы булганга көнләшеп йөргән. Әйе, иске, әйе, тутыгып беткән, ләкин барыбер машина инде. Кайчан телисең, кая телисең, утырасың да китәсең дип уйлаган ул. Тик Мирзаһит дустын кисәтеп куйган:

– Их, Вәли, Вәли, машинам бар дип шатланма, машинам юк дип кайгырма!

Вәли берни дә аңламаган. Берничә ел акча җыйганнан соң, ниһаять, хыялын тормышка ашырган – тотылган җиңел машина сатып алган.

Шунда ук аны сатып алу гына җитми, ә район үзәгендә техосмотр узарга, страховка ясарга кирәк икәнлеге ачыкланган. Өстәвенә, элекке хуҗасы кисәтеп куйган: машина иске, бензинны һәм майны күп ашый. Җитмәсә, тәҗрибәсез Вәли авариягә эләгеп, төнен юл инспекциясендә документлар белән мәш килеп уздырган. Машинаны алар Мирзаһит белән ике атна ремонтлаганнар. Ә бер айдан аңа "бәхет хаты" килеп төшкән: камера район үзәгенә барган чакта Вәлинең тизлеген арттыруын язып алган.


– Булды, җитте! Сатам бу баш бәласен! – дигән чыгырыннан чыккан Вәли. – Бутимер тагарактан күңелсезлекләр генә!

– И-и, дускай, машинаны алу гына җиңел, сатуы авыр... – дигән тәҗрибәле Мирзаһит.

Менә шунда Вәли Мирзаһитның кайчандыр әйткән сүзләрен искә төшергән:

– Машинам бар дип шатланма, машинам юк дип кайгырма...

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ



АМУР ФӘЛӘХ КЫТЫКЛАРЫ

КҮРЕНМӘС КЕШЕ САТТЫ

Ул елны кышкы каникуллардан соң көннәр кинәт җылытып, яңгыр яуды. Аяк асты – боз.

Яңа Комазан башлангыч мәктәбенең беренче сыйныфында укып йөрим. Өебез якын гына. Гадәттәгечә, озын тәнәфестә өйгә кайттым да, бераз капкалап алгач, кире мәктәпкә йөгердем. Мәктәп тыкрыгына җиткән идем инде. Лып! Таеп китеп күлдәвеккә утырдым. Кире кайту турында уйлау да юк, тиздән дәрес башлана.

Шыпырт кына класска кереп утырдым. Сизәм: чалбардан шыбыр-шыбыр су ага. Укытучы апа мине такта янына чакырмаса гына ярый инде...

Берзаман сыйныфташларым көлешкәнгә сискәнеп киттем.

– Амур күренми торган кешеләр белән сугыша, – ди партадашым Муллахан.

Фантастик әсәрләрне сыйныфташларым белән ярыша-ярыша укыйбыз анысы. Г. Уэльсның “Күренмәс кеше”се, Ж. Вернның “Җир үзәгенә сәяхәт”е кебек китапларны хәтта әнием кайдандыр сатып та алып кайтты.

Бактың исә, җылы бүлмәдә, тәрәзәгә капланган өленгә ярыгыннан керүче кояш нурында оеп киткәнмен. Тәнәфес вакытында класста күтәрелгән тузан, кояш нуры белән кушылгач, ниндидер сихри, алтын сызыкны хәтерләтә. “Ычкынып китеп”, әлеге сызыкны бармакларым белән “бүлгәләп” утырам икән. Шул “күренмәс кеше”ләр аркасында харап булдым бит!..

– Фәләхов, бас әле, нишлисең син анда? – диде укытучы апа.

Сикереп торып бастым һәм... үкенеп тә куйдым.


– Оһо-һо, ул бит астына пес итеп утыра икән, – ди Муллахан, минем әле дә су тамып торган чалбарыма ишарәләп.

Сабакташларым янә эчләрен тота-тота көләргә керештеләр. Гарьлегемнән елап җибәрдем. Бераз тынычлангач, ничек бу хәлдә калуымны аңлатып бирдем.

Ни генә булмасын, сабакташларым мине хөрмәт итә иде. Шуңа күрәдер дип уйлыйм (бәлки курыкканнардыр), беренче сыйныфта булган әлеге вакыйганы урта мәктәпне тәмамлап, төрлебез төрле якларга таралышканчы, бер генә кеше дә телгә алмады...



Эрнест ДЫШАЕВ, 2001 г.



Леонид НАСЫРОВ, 1970 г.



• • •

Колакларын актармасыннар өчен, мамык таякчыклары куллануны тыйдылар. Болай да күпләрнең башында гел мамык кына.

• • •

Базарда.

– Җиләк-җимешләрегез өлгергәнме?

– Өлгергән, өлгергән!!!

– Ә өлгергәнлек аттестатлары бармы?!

• • •

– Иремне һәрчак истә тотар өчен, мин аның карточкасын кесәмдә йөртәм.

– Бир әле карыйм.

– Банк карточкасы шул бу.

• • •

Эшләүче кешеләрне саклагыз! Әгәр алар үлеп бетсә, гел тикшерүчеләр һәм күзәтеп торучылар гына калачак!

• • •

– Кадерлем, бүгеннән башлап мин эчүемне ташлыйм!

– Ә кем миңа матурым дип әйтәчәк соң?!

• • •

– Карале, нинди кызык рәсем ясалган синең аягыңа, ул нәрсәне аңлата?

– Варикозны әйтәсеңме…

• • •

Хатыны иртән иренә әйтә:

– Син тагын төшеңдә сөйләштең.

– Әй Аллам, миңа инде төштә дә бер сүз әйтергә ярамый!

• • •

Әгәр спектакльнең беренче бүлегендә стенада мылтык эленеп торса, икенче бүлектә, һичшиксез, участок полициясе киләчәк һәм сиңа корал саклау кагыйдәсен бозган өчен штраф салачак.

• • •

– Кеше маймылдан барлыкка килүе дөрес микән?

– Син әле Җир дә түгәрәк дип әйтерсең!

• • •

Рәсәйдә ришвәтнең дүрт төре бар: укытучыларныкы, врачларныкы, гаишникларныкы һәм, ниһаять, мәҗбүри ришвәтчелек – гади халыкта ул "түрәләрнеке", юридик мәгънәсе – җәзага тартылмый торганы.

Валентин ДУБИНИН





3





ПЛЯЖ – БЕТКӘН

Хөрмәтле редакция! Барыбызга да мәгълүм, безнең республикада күлләрнең һәм елгаларның күп булуы, әле ул андагы пляжларда кызынучы халыкның мыжлап торуына чагышмый. Кайчагында эссе көннәрдә коеныр урын тапмассың – йә суы пычрак, йә яры яраклаштырылмаган яки байларның коттеджлары белән томаланган.

Ә менә Имәнкискә авылына уңайлыклар Ходай тарафыннан бирелгән. Чулман ярларына табигать менә дигән итеп ком җәйгән. Башка җирдә юк ул мондый күренеш. Күп еллар инде бу төшләр авыл кешеләрен, бакчачыларны һәм казанлыларны җәлеп итеп тора. Ләкин күптән түгел табигатьнең әлеге могҗизасына кеше кулы керә башлады. Янәмәсе ярларны ныгыталар, Чулман белән Брысса инеше кушылган урында биш метр биеклектә стена торгыздылар, һәм әлеге гамәл Брысаның өчтән бер кушылган җирен каплауга китерде. Комлы пляждан, аннан соң суга төшү урынының эзе дә калмады.

Элек монда ләкләкләрне күреп сокланалар иде, хәзер менә чүп өеме генә җыела, аны дулкын әлеге дә баягы торгызылган стенага бәреп тора. Ә түрәләр проекты буенча һәм экологларның килешенеп куелуында пляж бөтенләй каралмаган.

С. ӘХМӘТШИН

ЛАЕШ районы.

БӘДРӘФЛЕ МИЛЕК

Кадерле "Чаян!" Әйтәләр бит, әгәр сез түләүле бәдрәфләрдәге бәяләр белән килешмисез икән, димәк, сезгә әле килеп терәлмәгән. Ә менә чистайлылар Карл Маркс урамындагы автовокзал бинасындагы түләүле бәдрәф эшләвеннән канәгать түгелләр. Закон буенча мондый урыннарда бәдрәф хезмәте бушлай булырга тиеш икән бит. Анда кереп хаҗәтеңне үтәп чыгу 15 сум гына, югыйсә ләкин пассажирлар барыбер зарлана һәм ачу белән куак арасына керүне кулайрак күрәләр. Болай итү шәһәрдә уңайлылык тудыру хезмәтенә төкереп карау булып чыга.

Бу мәсьәләдә дөреслеккә ноктаны шәһәр башкарма комитеты куйды: бәдрәф шәхси кешегә бирелә – вокзалы-ние белән һәм тирә-юньдәге җирләре дә аңа кагыла. Димәк, яңа хуҗа яңа бәя куярга хокуклы, пассажирларның бернинди ай-ваена карамый. Менә шундый тантана килеп чыга әлеге мәсьәләдә!

В. БӘЙРӘМОВ

ЧИСТАЙ



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Валерий ТАРАСЕНКО

Рөстәм ЗАРИПОВ

@

Ошбу билге – татарча эт,
Урысчадан калька
Ни өчен, чөнки аларда
Бу тамга – "собака"...

Украин, "әкәм-төкәм", –ди
Швед – "фил борыны",
Кытайлар – "тычкан", – дип таный,
Фин – "мәче койрыгы",

Латыш, литвалар да "et", – ди,
"А" хәрефе өстәп...
Безгә дә туры килә ул,
Теккән кебек үлчәп...

...Башка атама булсын, дип
Көрәшмибез нишләп?
Безнең өчен иң кулае
Булыр кебек "ишәк"...

Кемдер әйтер, барс бик шәп,
Йә булмаса –бүре...
Җавап: " Алар бездә бик аз,
Ә чучкалар – мүре..."



БӨЕК! ДАҺИ! ИЛАҺИ!

Рафаэль Сәхәбиев... Аны әдәби җомга кичләрендә, яшь язучыларның иҗатларына багышланган семинарларда еш очратам. Шигырьләр язмый, ләкин һәрвакыт шагыйрьләр белән. Үз буыны шагыйрьләре белән. Җырлары да күбрәк шул буынныкы.

Иҗат учагы. Кайчандыр Сәйдәшләр, Тинчуриннар, Җәлилләр дөрләтеп җибәргән дуслык учагы. Шул учак тирәсендә мин тезелеп утырган бик күп әдип, шагыйрьләрне, композиторларны күрәм. Анда Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Нәҗип Җиһанов һәм Заһид Хәбибуллин да, Әхмәт Фәйзи, Нәкый Исәнбәт тә. Күп алар, йөзләрен шул зур бер учак яктырта. Хәзер дә ул учакның сүнгәне юк. Сара Садыйкова, Рөстәм Яхиннарның шагыйрьләр белән озак елларга сузылган иҗат дуслыгы шул турыда сөйли. Бер үк учак, тик буыннар гына башка. Композитор, шагыйрь һәм җырчы... Иң зур опера әсәрләреннән башлап, ике-өч минутлык лирик җыр да шушы өчлектән башка тумый.

Сәхәбиев... Түбән Кама районы, Шаңгәлче авылы егете. Иң беренче яратып уйнаган, җырлаган җыры "Умырзая". Берәүләрне ул озата, берәүләрне каршы ала. Иҗат ишеген "Умырзая" кага.

Сәхәбиевне җыр, моң белән сихерләгән кешеләрнең берсе – Марс Макаров. Башта баяны сихерли, аннан көйләре белән. "Кара шәле килә сөйрәлеп" Марс Макаров иҗатының, бәлки, кульминацияседер. Ул Рафаэльнең дә төп җыры.

Кайчакта җырчылар шулай бер җырда ачылып бетәләр сыман. Илһам Шакиров – "Кара урман"да, Зөһрә Сәхәбиева – "Җидегән чишмә"дә.

Рафаэль опералар белән генә чикләнми. "Самат"та ул – Ислам, "Җиһангир"да – мулла малае, "Евгений Онегин"да – Онегин. Үз буыны җырчылары арасыннан мин аның тавышын танырга телим: бу – Сәхәбиев.

Сибгат Хәким, *Татарстанның халык шагыйре.*

Язучылар белән дус булу һәммә артистка да язмаган. Без Рафаэль Сәхәбиевның чит илдән яисә Россиянең ерак шәһәрләреннән гастрольләрдән кайтуын көтеп алабыз. Чордашлары гына түгел, Сибгат Хәким, Нәби Дәүли, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев кебек олугларыбыз да аны тиң күрәләр иде. Аяз ага: "Слушай, парин, "Өянкеләр"не җырла әле", – дип, төркемнән читкәрәк тартыр да... Рафаэль ялындырмыйча көйне башлауга ук, Аяз аганың күзләреннән яшь бәреп чыга

Сезгә эндәшми, мин кемгә
Эндәшим, өянкеләр?
Җитте минем дә сезнең күк,
Картайдым, дияр көннәр...

Аннары өлкән әдип аның иңенә кулын сала да... җырның "Минем таныш өянкеләр, сезгә баш ияр кемнәр?" дигән төшенә җиткәч, сулык-сулык итеп, таралып елый башлый.

Ул елларда "Мин дә шигырь яза алам, мин дә көй чыгара алам, мин дә җырлый алам..." дигән хәзерге кебек тинтәк-тәвәккәлләр юк дәрәҗәсендә, бу изге гамәлне профессионаллар гына башкара иде.

Марсель Галиев, *Татарстанның халык язучысы.*

Газинур МОРАТ

РАФАЭЛЬ СӘХӘБИГӘ

Безнең дә бит еллар учагында
Бераз инде гомер көйрәде...
Бишегемне тибрәткәндә, әнкәй
Кайсы көйне икән көйләде?

Кай җыруны ул җырлады икән?
Хәтереңдә булса, әйт, йөрәк, –
Галәм бишегендә ятимнәр бар –
Юатырга кирәк!
Җыр кирәк!

Рафаэль Сәхәбиев – лирик баритонга ия җырчы. Бик талантлы һәм музыкаль актер. Миңа аның белән театрыбыз сәхнәсендә бик күп классик һәм милли репертуарлы спектакльләрдә җырларга туры килде. Башкаручы буларак, Рафаэль бик тә оста, үзеннән чыгарып кызык кына өстәмәләр кертә, шуңа күрә ул катнашкан спектакльләр аеруча уңышлы үтә иделәр. "Севильский цирюльник"тагы Фигаро булсынмы, "Дон Паскуале"дагы Маласеттамы, "Фауст"тагы Валентинмы. Бигрәк тә музыкаль спектакльләрдә уйнаган рольләре халык күңеленә ошый. "Башмагым"дагы Вафа, "Летучая мышь"тагы Айзенштейн, "Сильва"дагы Граф – тамашачыны шаккаттырды. Рафаэльнең мәзәкчәнлегеннән халык эче катып көлә иде.

Аның тагын бер табигый үзенчәлеген Ходай җәлләми биргән. ул режиссер буларак та үзен бик яхшы күрсәткәләде.

Зилә СӨНГАТУЛЛИНА, *Татарстанның һәм Россиянең халык артисты.*

Җырчыларның шагыйрьләр белән аралашып, дуслашып яшәве бер дә гаҗәп түгел. Киресенчә, бу нәрсә җырчыны да, шагыйрьне дә баета гына төшә. Аннары җырчы шагыйрь белән композитор арасында күпер ролен дә үти бит әле.

Көннәрдән бер көнне Татарстан Язучылар берлегенең пропагандада бюросы аны шагыйрьләр белән авылга чыгарга чакыра. Уттай урак өстендә, колхозчылар белән очрашып, аларның күңеленә дәрт, талган беләкләренә куәт өстәргә кем каршы килә инде?!

Юлга чыгарга вакыт җиткәч кенә, баянчының авырып китүенә беләләр. Нишләргә? Авылларга хәбәр ителгән, халык көтә. Шул вакыт Рафаэль: "Әйдәгез, киттек, үзем җырып чыгармын", – ди. Һәм чыннан да сынатмый.

Кыяфәте – чын француз,
Тавышлары – итальян.
Буй-сыны ул Европадан,
Моңны татардан алган.

Разил Вәлиев, *Татарстанның халык шагыйре.*

БӨЕК ҖЫРЧЫГА!

Чуарланды эстрада, операбыз сүнде,
Китеп бетте олпат җырчылар?..
Чишмәләр дә кибә, елга-диңгез сайый –
Бушлык белән тулган бу чорлар...

Нәрсә булып бетәр алгы көннәребездә,
Йә, кем әйтер чып-чын дөресен?
Баюына шашкан адәмнәрнең, уф...
Юньле уе юктыр, күрәсең?..

Бетәбез бит, сезнең белән бергә дөмегеп,
Болай барсак, юк ул киләчәк...
Сатылган ил, зур байлыгы – халкы таланып,
Бәддогасын җырлап үләчәк!

Шундый уйлар туды һәр зур җырчы боегып
Киткән чакта җырдан мәңгегә.
Бөек җырчы иде Рафаэль Сәхәбиев –
Һәм ул шундый хәзер, әле дә!

Алмаз ХӘМЗИН

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сезгә, оста язучы – Җәүдәт Юнысовның үз туган телендә – мишәрләребез диалектында сөйләменең матур үрнәге итеп бирердәй юморескасын тәкъдим итәбез.

Эшкә урнашма келәгән идем, сразы алдылар

– Мына былаерак булды бу халь.

Бардым. Кердем. Кадрлар бүлегенең ишеген тибеп ачтым.

Начальнигы утыра. Миннән дә яшерәк бер малай бит, тәре. Креслосы зур, үзе йымгак хатьлек кенә. Миңа карады да, "фыңгышт" иттереп, бырынын суырып алды. И, маңка тәре, мәтәм. Шынди зур фирмыда шынди пыльдырны начальник итеп куяларммы сың инде.

Ну, бай фирмы бит бу. Газпромның бер китеге. Мында, мәтәм, халык зерә крутуй. Шының әчен телевизырдагы кебек кылынып, каршындагы утыргычка утырдым, пытларымны мының эстәленә күтәреп куйдым и кычкырдым тегенәргә:

– Хай, – мәтәм.

Миңа туп-туры карады да:

– Иван, – диде.

– Юк, – мәтәм, – хайван тегел мин.

– Кемсың, – ди.

– Давыд, – мәтәм.

– Теге ниме әллә, – ди бу, пышылдабрак итеп.

– Юк, – дим, – яврәй тегел, чип-чиста Чистай татары.

– Один чурт, бетенегез шул кауымнан.

Дерес әтә инде анысы.

– Кагазең бармы сың? – диеп тепченә башлады.

– Нинди кагазь? – мәтәм.

– Син тиле тегелме? – ди.

– Юк! – мәтәм.

– Ват шының турында кагазь.

– Аның турында кагазь буламы, – димен аптырап.

–Нәрсә турында? – ди.

– Син тилеме әллә? – мәтәм.

– Тегел! – ди.

– Кагазең бармы сың? – мәтәм.

– Каян килсен?

– Ват шылай булгач, миңа каян килсен ул?! – мәтәм.

Шылай итеп, бу аңный башлады ахырысы минем Юашка урамыннан кергән прастуй гына малай тегел икәннекне.

– Ну, – ди, – әлсәк диплум бардыр?

– Миндәме? – диеп сырадым, аңнамаганга салышып.

– Юк, миндә, – ди.

– Синдә белмим, миндә биш, – мәтәм.

– Алай булгач, сиңа нәрсә гитмисың? – ди мескен.

– Гитә! – мәтәм.

– Ник мында кердең ату?

– Утырырга кердем, – димен.

– Утырасың бит инде, тагын кая утырма келисең? – ди. Мәтәм:

– Бүтән урынга, – дим.

– Бүтән урынга мында утыртмилар бит, прокуратурыда утырталар.

– Кая утырталар?

– Ну, тегендә инде, термәгә!

– Мин ул тырмыш мәктебендә утырып чыктым инде, энекәш, тыр минем урыннан, – дидем дә Шәрип Кәрибычның приказын эстәлгә ыргыттым. – Укы, мәтәм.

Укыды. Бер кат утырып укыды. Икенче кат тырып басып. Аннары утыргыч аягына абынып егылды да, тырып баскач, эченче кат укыды.

Бу кабинетта хазер мин начальник. Гендиректор Шәрип Кәрибычның биш дипломлы племяннигы.

Килегез! Эш кирәксә, керегез! Табылыр урын, мында кабинетлар күп...

КОНКУРС!

Кадерле дуслар! Туган тел һәм халыклар бердәмлеге елында "Чаян" журналы редакциясе "Чаянча чагу" дип исемләнгән юмористик хикәяләр конкурсы игълан итә.

1 июльдән 2021 елның ахырына кадәр сез редакциягә үзегезнең шаян хикәяләрегезне җибәрәсез. Без, үз чиратыбызда, аларның иң шәпләрен сайлап алабыз, журналда бастырабыз һәм авторларны акчалата призлар белән бүләклибез.

Җиңүчеләр өчен бүләкләр:

беренче урын өчен – 15000 сум;

икенче урын өчен – 10000 сум;

өченче урын өчен – 5000 сум.

Үзегезнең әсәрләрегезне редакциягә җибәргәнче chayan.ru сайтында конкурсның шартлары белән танышыгыз.

Хикәяләрегезне көтеп калабыз! Конкурста уңышлар сезгә!



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 7 (1908) июль 2021

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде. Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 02.07.2021 ел.
Тираж – 3374 Заказ Е-2239


Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru

16+

Бәясе ирекле

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Вакытны кайчан туктатырга була?

2. Борыныңнан тартып йөрмәсеннәр өчен нишләргә кирәк?

3. Күп эшләгән кешене ничек дип атарга?

4. Бердәнбер нинди спорт төрендә күнегүләр үткәргән вакытта ятып торырга ярый?

5. Нинди транспорт соңгы тукталышка хәтле алып бара?

6. Көн саен ресторанга йөри торган кеше?

7. Терелтеп булмый торга сәламәт кеше?

ҖАВАПЛАР

1. Ком сәгатен әйләндереп куйгач. 2. Кирәкмәгән җиргә борыныңны тыгып йөрмәскә. 3. Салым түләүче. 4. Бокс. 5. Катафалк. 6. Официант. 7. Тушамга төкерәп ятучы.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Ринат МӘННАН

УКУЧЫГА

Чын егет ул – безнең журнал.
Аның үткән каләме
Ярып сала кимчелекне!
Нык бел син шуны, яме?!

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 6 нчы санындагы чаянвордның тикшерү сүзе – **«ИСКЕ КАРА УРМАН»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Н. ЙОСЫПОВА (Арча р-ны, Яңа Кишет ав.),
Р. САФИН (Балык Бистәсе р-ны, Полянка ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан),
Р. ШӘРИПОВ (Казан).

Җиңүчебез – Яңа Кишеттән

Надия ЙОСЫПОВА!

Вячеслав БИБИШЕВ






Безнең бу вернисажыбыз арабыздан иртә киткән, Казанның иң күренекле һәм талантлы карикатурачыларының берсе – **Вячеслав БИБИШЕВның** рәсемнәреннән тора. Ул күпсанлы темалар һәм рәсемнәр авторы гына түгел, ә кызыклы проектлар, күргәзмәләр, төрле чаралар оештыручы да иде. Вячеслав Россия һәм бөтендөня конкурсларында катнашып, анда призлар һәм бүләкләр, ә Габровода Гран-при алган кеше. Ләкин аның төп иҗат мәйданы һәрвакыт «Чаян» битләрендә булды.







4612750670080